КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 2 ноябрь г.Казань № 1009

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник офтальмология хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә профессор Е.В.Адамюк исемен бирү турында

Казан офтальмология мәктәбенә нигез салучы профессор Емелиан Валентинович Адамюкның исемен мәңгеләштерү максаты йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник офтальмология хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә профессор Е.В.Адамюк исемен бирү турындагы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тәкъдимен кабул итәргә һәм алга таба «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Е.В.Адамюк исемендәге Республика клиник офтальмология хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе дип йөртергә.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына 30 көн эчендә «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник офтальмология хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе уставына тиешле үзгәрешләрне кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин